РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2021 г. г. Альметьевск № 35

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм түләү күләмнәренең торышы турында» 2015 елның 10 декабрендәге 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 ноябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, бюджет акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеге принцибын үтәүне һәм республика законнары нормаларына туры килүне тәэмин итү максатларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу уңаеннан бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм түләү күләмнәренең торышы турында» 2015 елның 10 декабрендәге 36 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 381 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 6 пунктта түбәндәге эчтәлекле 6.1 пунктча өстәргә:

«6.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бүләкләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләре булмаганда түләнә. Тиешле еллар эшләгән ечен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда, тиешле еллар эшләгән ечен пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү мондый түләү сорап мөрәҗәгать иткән кеннән башкарыла».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

Заказ № 2625

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Грушин А.И.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов